



# ТУГАН ЯК
# РОДНОЙ КРАЙ

ГАЗЕТА СЕВЕРО-ЗАПАДА ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ № 3 (6) МАРТ 2009

## НОВОСТИ ТАТАРСКОГО МИРА

### ЗАСЕДАНИЕ БЮРО ИСПОЛКОМА ВКТ

27 марта с.г. состоялось очередное заседание Бюро Исполкома Всемирного конгресса татар. На повестку дня были вынесены следующие вопросы:

— Утверждение Программы развития татарского населения регионов РФ на 2010–2020 гг.;

— О ходе подготовке к международной акции «Мин татарча сөйләшәм!»;

— О создании при Исполкоме ВКТ татарского дискуссионного клуба;

Рассмотренные пункты повестки дня вызвали оживленное обсуждение и интерес присутствующих. В ходе обсуждения данных вопросов были обговорены их наиболее узкие и проблемные места и предложены варианты решений.

### ТИҮ-НЕҢ ЮБИЛЕЙ КОРЫЛТАЕ УЗДЫ

Шимбә, 28 мартта, иртәнге сәгать унда "Казан" милли-мәдәни үзәгендә Татар иҗтимагый үзәгенең юбилей корылтае ачылды. Милли җыенга барлыгы 290 делегат килде. Җыен башында ук Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров корылтай делегатлары каршына тәбрик сүзе белән чыкты.

### ВСТРЕЧА С ПРЕДСТАВИТЕЛЯМИ ФИНЛЯНДИИ

В Исполкоме Всемирного конгресса татар состоялась встреча с советником по вопросам культуры посольства Финляндии в Москве с госпожой Черстин Кронвалл, сотрудником Министерства экономики Финляндии господином Кари Талвитие. В ходе беседы Председатель Исполкома ВКТ Р.З.Закиров рассказал о разносторонней деятельности Татарского конгресса. Особое внимание было уделено вопросам двуязычия в Татарстане, а также работе с соотечественниками в странах дальнего и ближнего зарубежья. В частности была подчеркнута плодотворная работа с обществом татар Финляндии «Исламия» во главе с Окан Дахером. Стороны отметили также развивающееся сотрудничество между Татарстаном и Финляндией.

**(Из сайта ВКТ).**

### ӘСӘКӘЙДӘ ОЧРАШУ БУЛЛА

22 апрельда район мәдәният йортында халкыбызның күренекле шагыйрәсе, Татарстанның атказанган мәдәният эшлеклесе Резеда Вәлиева белән очрашу була. Программада: Г.Тукай һәм Р.Вәлиеваның иҗаты белән танышу һәм аларның шигырьләре сәхнәдән яңгыраячак.

### В АЛЬКИНО ТУКАЕВСКИЕ ЧТЕНИЯ

В селе Алькино Похвистневского района, Самарской области 21 апреля состоится конкурс среди школьников, посвященный дню рождения Габдуллы Тукая. Ожидается приезд гостей и участников из Оренбургской области и Татарстана.

### НАВРУЗ ПРИНЕС СОЛНЦЕ И ВЕСНУ

Праздник Навруз байрам весело прошел 21 марта в Асекеево. Работниками культуры была представлена замечательная праздничная программа, выдержанная в народных традициях. Вначале Навруз был древним иранским земледельческим праздником. Крестьяне испокон веков отмечали его как начало весенних полевых работ, сопровождая веселье привычными ритуалами, призванными способствовать обильному урожаю. Татары же с большим энтузиазмом и масштабностью отмечают окончание полевых работ, всем известным Сабантуем.

### НАШИ БОРЦЫ СНОВА В ПРИЗЕРАХ

28-31 марта в Новосергиевке, в рамках «Старты надежд», состоялись соревнования по грекоримской борьбе. В общекомандном зачете наши спортсмены заняли третье место. В личном зачете, в своих весовых категориях Альберт Абдрахманов занял первое место; Руслан Галимов, Марат Ганеев и Артур Мязин — вторые места; Эхтияр Насретдинов — третье место. До соревнования ребята тренировались на сборах, которые были организованны в ОАО «Алга». Руководитель хозяйства И. Давлятов обеспечил спортсменов питанием и проживанием. Он же выделил для победителей соревнований солидные денежные премии.

"АК ХИСЛӘР"

# УЙНЫЙБЫЗ ДА, ҖЫРЛЫЙБЫЗ ДА

Әсәкәй татар активистлары үзләренең эшләрен туган телне, мәдәниятне саклауда һәм үстерүдә күрше тирә-якдагы татарлар күпләп яшәгән авыл һәм шәһәрләр белән бергә алып барырга ниятлиләр төбәкара татар мәдәнияте ассоциясе төзеп.

Шушы уйның беренче адымнары булып "Ак хисләр" фестивале алдыннан үткәрелгән ике очрашу булды. Өченче мартта Богырыслан шәһәрендә танылган язучы — журналист Мәскәү каласыннан Нәзифә Каримова, Рәсәйнең һәм Татарстанның атказанган артисткасы Наиля Фатехова белән күңелгә ятышлы концерт-очрашу булды. Бу чарага килгән кешеләр күңеленә туган телебезнең олы кодрәте, тирән мәгънәсе Нәзифа Каримованың чыгышында тасвирланды.

А Наилә Фатехова башкаруында халкыбызның һәм артистканың үзе язган җырлары беркемне дә битараф калдырмады. Залда утырган яше-карты Нәзифа Каримова шигырьләренә язылган җырларны көчле алкышлар белән үзләренең хисләрен аңлаттылар.

Шул ук кичне 3 мартта күрше өлкә Самара ягында яшәгән Гали авылы татарлары алдында Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев һәм журналист Гөлназ Шйхи очрашу үткәрделәр.

Дуртенче мартта Әсәкәй район мәдәният йортында быел төбәкара "Ак хисләр" фестивале үтте.

Алты район һәвәскәрләре үзләренең осталыгын җырда, биюдә, фольклор, нәфис сүз жанрларында күрсәттеләр.

"Ак хисләр" фестиваленең "Гран-При" бүләгенә вокал жанрында Иске Мөъмин авылы Әсәкәй районы егете Радик Ганиевны лаек дип жюри карар чыгарды. Ул төсле телевизор белән бүләкләнде.

Беренче дәрәҗәле дипломга җырчы Аделя Юнусова Северный районнан лаек булды — кухонный комбайн белән бүләкләнде.



Фольклор жанрында Яңа Солтангол авылы балалар бакчасы фольклор ансамбле "Каргатуй" исемле чыгышы өчен беренче дәрәҗә дипломга лаек булып кыйммәтле бүләк алды.

Башка район һәвәскәр артистлары икенче, өченче дәрәҗәле дипломнар һәм бүләкләр алдылар.

Самара әлкә Гали авылыннан; Абдулино районы Якуп авылыннан; Пономаревка районы Нуруз, Дусмәт авылларыннан; Северный районы Бакай авылыннан; Богырыслан шәһәреннән килгән һәвәскәрләр барсы да төрле жанрларда чыгыш ясап "Ак хисләр" фестиваленең истәлекле бүләкләрен һәм грамоталарын алып киттеләр.

Фестивальнең биш еллыгын 100 дән артык һәвәскәр артистлар Наиля Фатехова башкаруында Нәзифа Каримова шигыренә кушылып җырлап тәмамладылар.

**Зәйтүнә ВАЛИШИНА.**

**На снимках:** выступают гости из Москвы и Казани.



ИЗ ЗРИТЕЛЬНОГО ЗАЛА

# РОДНИКИ СВЕТЛЫХ ЧУВСТВ





В начале марта, в районном Доме культуры проводился фестиваль «Ак хисләр» — «Светлее чувства». Хотелось бы поделиться впечатлениями об этом событии в культурной жизни района и области. Фестиваль областного значения, а теперь уже, наверное, и межрегиональный. За пять лет круг участников фестиваля существенно расширился. К нам стали приезжать и из других регионов.

Пожалуй, одно чувство доминировало во время просмотра этого мероприятия. Чувство восторга и гордости за земляков, но с примесью некоторой обиды. Обиды за то, что этот фестиваль некоторые проигнорировали, не придав ему должного значения. Но, пусть это будет на их совести. Нам же, зрителям, довелось участвовать на настоящем, незабываемом празднике. Нет, это не было обычным мероприятием культработников районного масштаба. Высокоорганизованная, профессиональная подготовка, квалифицированное жюри во главе с народным артистом Татарстана Минголом Галиевым, реальная путевка в творческую жизнь для действительно талантливых ребят — что может быть, как сейчас сказали бы, «круче»?!

Кстати, профессор Мингол Галиев проведет летом нынешнего года в Асекеево мастер класс по вокалу для талантливых начинающих певцов. Именно во время фестиваля, он увидел перспективных ребят — а это значит, что «Ак хисләр» удался.

Еще одна примета фестиваля — участие в нем артистов всех возрастов. Аксакалы села Алькино, на тальянках, своими мотивами уносили зрителей в прошлое. Тут же им на смену выходили малыши из детских садов Новосултангулова и Асекеева и тоже возвращали нас своими постановками к истокам. Люди старшего поколения не скрывали слез — значит, ничто не забыто, значит, еще живет в народе тяга к традициям и наследию. Выступления артистов действительно вселяли в нас светлые чувства.



Конечно, уровень выступлений по сути самодеятельных артистов был не одинаков. Но эта «изюминка», как бы придавало фестивалю свою особенность. Для начинающих на большой сцене, есть с кого брать пример, а для профессионалов предоставлена возможность роста.

А выступление в конце настоящих мастеров из Москвы и Казани придало мероприятию особый восторг. Многие ребята впервые выступали на одной сцене с именитыми артистами. Возможно, не все юные дарования выберут впоследствии сцену, но в памяти их, это событие останется навсегда.

Верно говорят в поговорке, что под лежачий камень вода не течет. Только благодаря энтузиазму культработников во главе с Зайтуной Валишиной, и об этом говорили со сцены гости из Казани и Москвы, «Ак хисләр» состоялся и стал уже традиционным. А моральная и материальная поддержка фестиваля депутатом Законодательного собрания области Ильдусом Давлятовым, придала этому мероприятию масштабность и солидность.

И зрители, и участники фестиваля, покидали Дом культуры со светлыми чувствами. Думается, только вот так, реальными делами, можно сохранить в народе культуру, язык и добрые традиции.

**Ф.ФАТТАХОВ**

**На снимках:** талантливые участники фестиваля; компетентное жюри.

ОБЩЕСТВЕННАЯ РАБОТА

# Теперь у нас есть Ассоциация

Знаменательное событие произошло 13 марта 2009 года в Бугуруслане. В Доме культуры имени Тукая, состоялось подписание Декларации, о создании межрегиональной Ассоциации татарских национально-культурных объединений "Бердәмлек". Пока, в Ассоциацию вошли три объединения: из Асекеева, Бугуруслана и села Алькино Самарской области. Но, здесь будут рады принять в свои ряды и других.

Разумеется, речь не идет о создании новой организации с юридическим лицом. Объединение, скорее, неформальное. Просто назрела необходимость координировать свою работу. Вот, например, в селе Алькино, оказывается, ежегодно проводится детский сабантуй. Школьники сами организуют и проводят этот праздник, при этом соблюдаются все традиционные обряды. Теперь, на этот праздник приедут дети и из Бугуруслана и Асекеева.

Все три объединения согласовали планы по культурно-просветительской работе. Общий план на год будет опубликован в нашей газете в следующем номере. А пока, предлагаем Вашему вниманию Декларацию этих объединений.

**На снимке:** участники Ассоциации обсуждают планы на год.



## ДЕКЛАРАЦИЯ

**о создании Межрегиональной Ассоциации татарских национально-культурных объединений Оренбуржья и Самарской области «Бердәмлек»**

*Татарская национально-культурная автономия Асекеевского района, Оренбургской области; Татарский общественный центр "Туган тел" города Бугуруслана, Оренбургской области; Культурно-просветительское общество "Туган тел" села Алькино, Похвистневского района, Самарской области — далее именуемые учредителями, объявляют о создании общественного объединения — Межрегиональной Ассоциации «Бердәмлек».*

*Целю создания Ассоциации является совместная, координированная культурно-просветительская работа на территориях компактного проживания татар.*

*Область деятельности Ассоциации: пропаганда культуры, традиций, наследия татарского народа, поддержка преподавания родного языка и литературы в учебных заведениях, развитие у детей интереса к истории народа, пропаганда межнациональной и межрелигиозной терпимости и любви к родному краю.*

*Область деятельности Ассоциации регулируется Уставами ее учредителей. Ассоциация не является юридическим лицом и работает на общественных началах.*

*Ассоциация оказывает организационную и иную помощь татарским средствам массовой информации, в том числе и газете северо-запада Оренбургской области "Туган як. Родной край"*

*Ассоциация ежемесячно проводит свои заседания, для координации и планирования совместных мероприятий.*

*Ассоциация открыта для других татарских национально-культурных объединений.*

***Председатель ТНКА Асекеевского района И. ДАВЛЯТОВ***
***Председатель ТОЦ "Туган тел" г . Бугуруслан Х.ГАЗИЗОВ***
***Председатель культурно – Просветительского общества "Туган тел" с. Алькино Р. ЛАТЫПОВ***
***13 марта 2009 года.***

СЕМЬЯ

# Үрнәк гаилә

Иске Солтангол авылында бер искиткеч гаҗәеп, матур, күркәм гаилә яши. Алар Закария белән Галия Калимуллиннар гаиләсе. Галия үзе 1948 елда 23 ноябрьда әнисенең өченче баласы булып доньяга килә. Галиянең әтисе Сафаутдин абый белән әнисе Фатыйма апа кызларын бик иркәләп, назлап, дөрес тәрбия биреп үстерәләр. Мәктәб елларында ук Галия бик оста җырлый, бии, гармунда, мандалинада уйнарга өйрәнә. Клубтагы бер бәйрәм концерты да Галиядән башка үтми. Ул анда җырлый, бии һәм концертларны алып бара.

Шул матур моңлы тавышлы җырлары белән, яшь-яшь чибәр кыз яшь егет Закариянең йөрәген яулап ала һәм алар 1965 елда көзге бәйлыкта өйләнешәләр. Алар икесе дә тырышалар, бар яклап та бик тә пар килгәннәр. Шулай итеп, пар күгәрченнәр кебек гөрләшеп, 44 ел бергә гомер кичерәләр.

Алар 16 ел Узбәкстан ягында яшиләр, әмма шулай да Иске Солтангылның кызыл таулары, матур Кенәле елгалары, тәмле чишмә сулары туган якка тартып кайтара аларны. 1985 елда Закария Әсәкәй заготконторасына заготовитель булып эшкә керә һәм шунда пенсиягә чыкканчы эшли. Ә Галия Әсәкәй госстрахына агент булып эшкә керә, чөнки ул Үзбәкстанда да 16 ел шул эштә эшләгән. Галия хәзерге көндә дә шул эшендә эшли. Эштә ул гел алдынгылар рәтендә. Шуңа күрә Галияне 2007 елда алдынгы эшче буларак, Госстрахка 85 тулу уңае белән, Мәскәүгә съездга җибәрәләр. Ул анда мактау кәгазе һәм кыйммәтле бүләкләргә лаек була.

Быел Галиянең 60 яшьлек гомер бәйрәме булды. Юбилей бәйрәмен алар искиткерлек матур итеп уткәрделәр. Алар барысына да ничек өлгәшә икән? Йортта мал-туар, эшкә барырга, үзешчән сәнгатенә катнашырга да вакытлары җитә. Алар ике кыз, бер малай тәрбияләп үстергәннәр, барсына да югары белем биргәннәр. Хәзер алар үзләре әти-әни булганнар. Галия белән Закариянең алты оныгы бар. Юбилей бәйрәменә барысыда кайтканнар, һәтта Үзбәкстан кода-кодагыйлары да котларга кайттылар. Бәйрәмгә Галиянең бөтен туганнары, балалары, хезмәттәшләре һәм дуслары җыелышып бик зурладылар. Юбиляр хөрмәтенә һәрберсенән бик күп җылы сүзләр әйтелде.

Галия апа белән Закария абый олыларны хөрмәт итеп, балалары, туганнары алдында үрнәк гаилә булып яшиләр. Шулай ук алар бик кунакчыл. Һәрберсенә ачык йөз күрсәтеп, ярдәмгә мохтаҗ булганарга ярдәм итеп торалар. Аларның йортлары һәрвакыт ямьле, пөхтә, пешергән ризыклары татлы.

Менә Иске Солтанголда нинди уңган-булган тату, кешелекле, матур гаилә яши.

**Нурзимә ГИЗЕТДИНОВА**
**Әсәкәй авылы.**

**Фотода:** Закария белән Галия Калимуллиннар.



АКТУАЛЬНОЕ ИНТЕРВЬЮ

# Очаг культуры не погаснет

**В одной из местных газет было опубликовано письмо, в котором сельчане выражали тревогу по поводу очага культуры села Михайловка. В свое время он принадлежал колхозу имени Ульянова, потом его правопреемнику — колхозу «Мир». Теперь у клуба новый хозяин.**

**Тревога авторов письма понятна. Для людей очень важно иметь возможность где-то собраться. Кому-то надо проявить свои способности на сцене, другой, напротив, хочет услышать «живую» музыку и песню, насладиться народным танцем, а молодежи и вовсе просто потанцевать хочется на дискотеке. И вот клуб, проработавший десятки лет, может быть закрыт или перепрофилирован.**

**Не секрет, что новым владельцем бывшего колхозного клуба стал бугурусланский предприниматель Хамзя Газизов. К нему мы и обратились за разъяснениями.**

**— Хамзя Ахметович, так что же будет с клубом?**

— Тревоги авторов письма мне понятны, но они безосновательны. Об этом я сказал еще на первом собрании членов вновь организованного ООО «Михайловское», которое, кстати, проходило в клубе. Но разговоры на эту тему не утихают, можно слышать даже такие бредовые домыслы, что я здесь хочу организовать конюшню, а то и вовсе оборудовать зерносклад. Иначе, говорят, зачем бы я его покупал.

**— И действительно, зачем?**

— Да попросту клуб, как и заинтересовавшие меня производственные помещения — конюшня, зерносклад, ангар — входили на аукционе в один лот. Так что волей- неволей пришлось покупать и его. Кстати, вышло это мне дороже. И, в конце концов, не купил бы я — купил бы кто-то другой.

Повторяю: клуб по-прежнему будет выполнять все функции сельского учреждения культуры. Я и сам в молодости туда ходил. Между мной и МО «Михайловский сельский совет» имеется соглашение — договор, при выполнении которого, очаг культуры будет передан в ведение администрации села Михайловка.

Но в любом случае закрывать или перепрофилировать его не буду. Пусть читатели не сочтут за похвальбу, но ведь я являюсь председателем татарского общественного центра, занимающегося возрождением и развитием культуры. Напомню и о школе татарской национальной борьбы Куреш, в которую вложил немало сил и средств. Так что значение сельского очага культуры хорошо понимаю.

Наше сельхозпредприятие будет строить свою деятельность на основе возрождения и развития отраслей животноводства, растениеводства, а также строительства и создания базы отдыха. Мы располагаем 1 500 гектарами площадей земельных угодий с пастбищами и сенокосными лугами. Очень прискорбно, но факт, в некоторых местах на них устроены свалки мусора, поля заросли сорняком.

Первоочередной задачей считаю приведение в нормальное состояние животноводческих ферм, пастбищ, сенокосов. Необходимо вспахать и все имеющиеся поля. Для работы в отрасли растениеводства приобретаются трактора: «К-700», «Т-150», «МТЗ-82» и «Т-4»со шлейфом почвообрабатывающей, посевной и уборочной техникой. Дел предстоит сделать не мало.... В нынешнем году планируем посеять 500 гектаров земель озимыми, а в 2010 году посевы зерновых значительно увеличим. Так что, клуб будет действовать, а сельхозпредприятие работать.

**Записал Виктор ТИНГАЕВ**
**Бугурусланский район.**

ТУЙ

# Мәҗлес табынында утыру кагыйдәләре

Табынның түрендә кияү белән кәләш (ул кияүнең уң ягына) утыра. Аның янына — егетнең әти-әнисе һәм шаһитлар, ә егетнең сул ягыннан кызның әни-әтисе һәм шаһитлар утыра. Шуннан инде өстәл буйлап кара-каршы кода-кодагыйлар утырырга тиеш. Ягъни өстәлнең уң ягына егет ягыннан килгән туганнар, сул ягына кыз ягындагы туганнар утыра. Шуны да онытмаска кирәк, кода каршысына — кода, кодагый каршысына кодагыйның утыруы бик мәгънәле һәм күңелле, чөнки аларның серләре уртак.

Башка кунаклар, дус-ишләр дә табын янында тиешле урыннарын табалар. Шуны әйтеп үтик, табын янында ир кешенең уң ягында хатыны утырса, сул ягына ир кеше утыра.

Әлбәттә, кем янына кемне утырту — хуҗаның үз эше.

Шунысы да бар, туй яки башка төрле мәҗлесләрдә кода-кодагыйдан соң, алар тирәсенә иң якын туган-тумачалары, дус-ишләре утыртыла. Бу инде аларны аеруча хөрмәтләүне аңлата.Башка төрле мәҗлесләрдә дә кунакларны утырту тәртибе туй табынынннан әллә ни аерылмый. Килгән кунаклар нәкъ шул тәртиптә утырып, алар арасыннан олырак яшьтәге кешеләрне хөрмәт йөзеннән иң түргә утыртырга мөмкин.

Чакыргач, кунак беркайчан да соңга калмыйча, вакытында килергә тиеш. «Ашка килсәң — элек кил, үз кадереңне белеп кил», диләр.

Өйгә килеп кергәч, кунак тәртип белән генә чишенә, аяк киемен, өс-башын теләсә кайда түгел, бәлки тиз генә алып киенерлек уңайлы урынга куя. Үзенен пөхтәлеген тикшерә, аннары алданрак килгәннәр белән күрешеп чыга. Хатын-кыз үзе кул биреп күрешә.

Кунаклар җыелып беткәч, мәҗлес хуҗасы аларны табын янына утырышырга өнди. (Башта кунак әйбәтләп кулын юарга тиеш).

Өстәл тирәсенә утырышкач, хуҗа кунакларны үзара танышытыра башлый, мәҗлес җыюның максатын әйтә, мәҗлесне ачып җибәрә, аны алып бару өчен кунаклар арасыннан — тамада, ягъни табын башы сайлана.

Тамада мөлаем, җор, тапкыр сүзле, юморлы кеше булырга тиеш. Ул — табынның чын хуҗасы, аның әйткәннәрен үтәү шарт. Җыр, бию, уен-көлке, тост тоту, мәҗлеснең тәмамлануын билгеләү — барысы да тамада карамагында. Әлбәттә, һәр нәрсә табигый, ә уен-көлке урынлы, чын күңелдән, башка кешене кимсетми торган булырга тиеш. «Ашның тәме — тоз белән, мәҗлес яме — сүз белән», дигәннәр.

Соңга калып килгән кеше булса, табын янында аның белән сузыла-сузыла кулыңны биреп күрешмә. Башыңны иеп кенә исәнләшү бик җиткән.

Утыра белү — бер инсаф, ашый белү — икенче инсаф. Аларның һәркайсы табынны матурлый.

Табынга килеп утыргач, тәзәтенеп, ясанып, хатын-кызга бизәнеп, ирен буяп утыру да килешми.

**Дәвамы бар.**

## Кадерле әниемә багышлыйм

Язмышлардан — узмыш юк шул,
Маңгайларга сырлар салып,
Чәчләрне иртә чаллатып,
Сугыш гәләмәтләре кичерде.
Кайгы — хәсрәт күреп,
күз яшьләрен түгеп
Кадерле әниебез безне үстерде.

Минем әнием гәйбәт сөйләмәде
Нахак сүзләр өйгә кертмәде;
Гел михербанлы, гел изгелекле иде
Кешеләргә булган хезмәте, хөрмәте.

Күзләреннән кайнар яшь тамада,
Кайнар кочагына алып безне яклады,
Авыр тормыш, ачы хәсрәтләрдән
Нәселем өзелмәсен — дип
Бар кыенлыктан безне саклады.

Әнкәемә һәм бар булган әрвахларга
Барсына бездән хәер — дога.
Нәсел җепләре өзелмәсен җирдә,
Еллар имин булсын, күкләр тыныч булсын,
Изге нурлар иңсен, кояш балкып торсын
Илаһым җир шарында.

**Клара ШАКУРОВА, Богырыслан шәһәре.**

## Авыл тормышы

**(хәзерге куренеш)**

Авылда яшәу күңелле,
Бер катлы кешеләре.
Һич нәрсәгә исе китми,
Булмаса да эшләре.

Күмәк хуҗалык таралгач
Эшкә куучы да юк;
Халык риза, ачтан үлми
Өс бөтен, тамагы тук.

Кайберәуләре генә
Акча диеп баш вата,
Я суган, кишер үстереп.
Я сәмәй куып сата.

Яшерәкләре эш эзли
Мәскәүдә, Самарада;
Икенчеләре буталып
Йөри ике арада.

Олыларның куанычы
Пенсия акчасында;
Бүтәннәрнең ышанычы
Мал-туар, бакчасында.

Хәзер авыл кешеләре
Яши коммунизмда;
Ачтан үлми, рәхәт күрми
Яталар инде шунда.

**Сафиулла ӘҺЛИУЛЛИН, Иске Мөъмин авылы.**






## Йомырка пельмәне

**500 гр онга камырга, 1 ст сөт, тоз, фаршка: 15 күкәй, 4 — 5 суган, 50 гр май, тоз һәм кара борыч.**

Камырны басарга, пельмәннекы кебек җәергә һәм, и дүрт почмаклап кисәргә. Пешкән йомырканы вак кына турап, суган, май белән суганны жарить итеп, тоз, кара борыч белән бутарга.Җәйгән дүрт почмаклы камырга пельмән кебек ясап, кайнап торган суда пешереп алып, тәрилкәләргә салгач, каймак яки майонез салырга.

## Фаршировать ителгән кабак

**Кабак — 500гр, ит — үзегез теләгәнчә, суган — 2 баш, тоз, борыч, — үзегез теләгәнчә.**

Кабакны 2-3 см аягыннан астарак ачарга да эчендәге тешләрен һәм җимешләрен чистартырга.Фаршны эченә тутырып өстен киселгән ягы белән капларга. 2-3 сәгатькә духовкага яки пичкә куярга. Фарш болай әзерләнә: итне вак кына турарга яки мясорубка аша үткәзергә, суган, тоз, кара борыч барысын бергә кушарга. Кабакны каймак яки атланмай яки майонез белән әзерләргә була.Табингa биргәндә кабакның тышын салдырырга, эчендәге мякоть белән фаршны тәрликәгә салырга.

Бик тәмле булыр.

**Клара ШАКУРОВА, Богырыслан шәһәре.**

## Әйтемнәр һәм фразалар

Агач тел. (тупас сүзле)
Агылыйга тагылый. (теләсә кемгә иярә)
Адәм актыгы / Адәм аламасы. (бик әшәке кеше) / Адәм имгәге. (бик булдыксыз я кеше өстенә калган кеше) / Адәм көеге. (җәфа, хәсрәт китерүче)
Адәм көлкесе (мәсхәрәсе). (хурлыклы эш-хәл) / Адәм хуры. (түбәнлекле)
Адәм рәтле. (ярарлык кимәлдә)
Ай күрде, кояш алды. (кыска булып кинәт беткән нәрсә тур.)
Айт дигәнгә тайт дип тору. (нәр йомышка әзер тору)
"Ай-һаенда юк". (гел дә уйламый)
Ак болытларда йөзү. (буш хыяллар)
"Акмаса да тама". (әз-әзләп керем керә)
Акны карадан аермау. (надanlык яки белексезлек)
"...Ак сакаллы карт булыр идем". (...эшем уңар иде)
Актан-карадан сүз әйтмәү. (бер якны да якламау)
Актык чиктә. (соңгы чара итеп),
"Акча бездә бер букча".
Акча сугу. (күп акча алу)
Акча түгү. (зур чыгымнар тур.)
Акыл сату. (белдекле булып сөйләнү)
"Акыл өләшкәндә абзар артында калган".
Акылга таман (сай, чамалы, җиңел) / [акылга] тулы түгел
Ал да гөл. (бик яхшы, бик шәп)
Алма апа. (ананың сеңлесе)
"Алла боерса" [Аллабирса] / "Алла теләсә"
Алла бәндәсе / Хода бәндәсе. (беркатлы, күндәм, саф күңелле)
Аллага тапшыру / "Аллага тапшырдык". (тәвәккәлләп башлау)
"Алла диген!" (бик узынма / яман сүз сөйләмә)

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ



(время местное)

| Апрель | Фаджр Иртә | Восход Кояш чыга | Зухр Өйлә | Аср Икенде | Магриб Ахшам | Иша Ясту |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 7-05 | 8-05 | 15-10 | 19-10 | 21-10 | 22-40 |
| 2 | 7-03 | 8-03 | 15-10 | 19-12 | 21-12 | 22-42 |
| 3 | 7-01 | 8-01 | 15-10 | 19-14 | 21-14 | 22-44 |
| 4 | 6-58 | 7-58 | 15-10 | 19-15 | 21-15 | 22-45 |
| 5 | 6-55 | 7-55 | 15-10 | 19-17 | 21-17 | 22-47 |
| 6 | 6-52 | 7-52 | 15-10 | 19-19 | 21-19 | 22-49 |
| 7 | 6-50 | 7-50 | 15-10 | 19-21 | 21-21 | 22-51 |
| 8 | 6-48 | 7-48 | 15-10 | 19-22 | 21-22 | 22-52 |
| 9 | 6-46 | 7-46 | 15-10 | 19-24 | 21-24 | 22-54 |
| 10 | 6-43 | 7-43 | 15-10 | 19-26 | 21-26 | 22-56 |
| 11 | 6-40 | 7-40 | 15-10 | 19-28 | 21-28 | 22-58 |
| 12 | 6-38 | 7-38 | 15-10 | 19-30 | 21-30 | 23-00 |
| 13 | 6-36 | 7-36 | 15-10 | 19-32 | 21-32 | 23-02 |
| 14 | 6-34 | 7-34 | 15-10 | 19-33 | 21-33 | 23-03 |
| 15 | 6-32 | 7-32 | 15-10 | 19-35 | 21-35 | 23-05 |
| 16 | 6-29 | 7-29 | 15-10 | 19-37 | 21-37 | 23-07 |
| 17 | 6-27 | 7-27 | 15-10 | 19-39 | 21-39 | 23-09 |
| 18 | 6-25 | 7-25 | 15-10 | 19-41 | 21-41 | 23-11 |
| 19 | 6-22 | 7-22 | 15-10 | 19-42 | 21-42 | 23-12 |
| 20 | 6-20 | 7-20 | 15-10 | 19-44 | 21-44 | 23-14 |
| 21 | 6-17 | 7-17 | 15-10 | 19-46 | 21-46 | 23-16 |
| 22 | 6-15 | 7-15 | 15-10 | 19-48 | 21-48 | 23-18 |
| 23 | 6-13 | 7-13 | 15-10 | 19-49 | 21-49 | 23-19 |
| 24 | 6-10 | 7-10 | 15-10 | 19-51 | 21-51 | 23-21 |
| 25 | 6-08 | 7-08 | 15-10 | 19-53 | 21-53 | 23-23 |
| 26 | 6-06 | 7-06 | 15-10 | 19-55 | 21-55 | 23-25 |
| 27 | 6-04 | 7-04 | 15-10 | 19-56 | 21-56 | 23-26 |
| 28 | 6-02 | 7-02 | 15-10 | 19-58 | 21-58 | 23-28 |
| 29 | 6-00 | 7-00 | 15-10 | 20-00 | 22-00 | 23-30 |
| 30 | 5-58 | 6-58 | 15-10 | 20-02 | 22-02 | 23-32 |

**Данные предоставлены Бугурусланским муфтиятом. Возможна разница во времени в сравнении с другими источниками, на 3-5 минут. (Время летнее).**

ТУГАН ЯК
РОДНОЙ КРАЙ

**УЧРЕДИТЕЛЬ:** ТАТАРСКАЯ НАЦИОНАЛЬНО КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ
**АДРЕС РЕДАКЦИИ:** С.АСЕКЕЕВО, УЛ.ЧАПАЕВА 24.
**ТЕЛЕФОН:** (353-51) 2-22-81

Распространяется в Асекеевском, Абдулинском, Бугурусланском, Матвеевском, Пономаревском районах.
Свидетельство о регистрации ПИ №ТУ 56-00065, выданное Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи и массовых коммуникаций по Оренбургской области.

Газета отпечатана в Бугурусланской типографии. 461600, г. Бугуруслан, ул. Революционная, 14.
Цена свободная. ТИРАЖ: 2000 ЭКЗ.

**Главный редактор: Фарит НУГУМАНОВ**

**E-MAIL:** tugan-iak-asekeevo@yandex.ru